Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлегенең Смәел торак пунктында ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
№ 2

22 ноябрь, 2025 ел.

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авылы торак пунктында гражданнар җыены карар бирә:

1. Балтач районының Смәел авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салым акчасын 650 сум күләмендә кертергә. 1 төркем инвалидларга, балачактан инвалидларга, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләргә, ялгыз өлкән пенсионерларга, Россия Армиясендә хезмәт итүчеләргә, Кораллы Көчләргә мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына 95% күләмендә, көндезге бүлектә укучы студентларга 50% күләмендә ташламалар ясарга.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::
торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:
- Смәел торак пунктының Бауман урамындагы асфальт-бетон өслекне ремонтлау;
- Смәел торак пунктының асфальт-бетон өслегендәге ярыкларны ямау.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Смәел авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Йосыпов